**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
**IV чакырылыш**
423740, Актаныш авылы, Ленин пр., 17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**IV созыва**
423740, село Актаныш, пр. Ленина, дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР**
**15.12.2023 ел**

**РЕШЕНИЕ**
**№33-06**

«Татарстан Республикасы «Актаныш муниципаль районы Советы, Башкарма комитеты, "Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы" МКУ, "Финанс-бюджет палатасы" МКУ, "Мәгариф идарәсе" МКУ, "Контроль-хисап палатасы» МКУ муниципаль вазыйфаларын биләүче һәм муниципаль хезмәткәрләр өчен премияләр һәм башка өстәмә түләүләр турында" 2023 елның 10 февралендәге 27-04 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Актаныш муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең эшчәнлеген стимуллаштыру тәртибен камилләштерү максатларында

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы «Актаныш муниципаль районы Советы, Башкарма комитеты, "Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы" МКУ, "Финанс-бюджет палатасы" МКУ, "Мәгариф идарәсе" МКУ, "Контроль-хисап палатасы» МКУ муниципаль вазыйфаларын биләүче һәм муниципаль хезмәткәрләр өчен премияләр һәм башка өстәмә түләүләр турында" 2023 елның 10 февралендәге 27-04 номерлы Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Нигезләмәнең 1 бүлегенең 1.7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль район Башлыгы, муниципаль район Башлыгының даими нигездә урынбасары, Совет аппараты җитәкчесе, муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесе, күрсәтелгән премияләрдән тыш, җирле бюджет акчалары исәбеннән эш йомгаклары буенча квартал саен матди бүләкләү, Татарстан Республикасы көненә, республика һәм федераль хакимият органнары күрсәтмәләре нигезендә җирле үзидарә көненә карата матди бүләкләү алырга мөмкин.»

1.2. Нигезләмәне түбәндәге эчтәлектәге 6 бүлек белән тулыландырырга:

«6. Пенсияләрне, отпускларны, вакытлыча эшкә яраксызлык буенча пособиеләрне исәпләү өчен уртача хезмәт хакын исәпләү тәртибе һ. б.

6.1. Әлеге Нигезләмәдә каралган һәм җирле бюджет хисабына түләнә торган квартал саен бирелә торган премияләр, шулай ук республика һәм федераль хакимият органнары күрсәтмәләре нигезендә түләнә торган эш йомгаклары буенча квартал саен бирелә торган матди бүләкләү, пенсияләр, отпusклар, вакытлыча эшкә сәләтсезлек буенча пособиеләр һ. б. исәпләү өчен уртача хезмәт хакы составында исәпкә алына.

6.2. Татарстан Республикасы көненә, җирле үзидарә көненә багышлап җирле бюджеттан бер тапкыр түләнә торган акчалата бүләкләүләр, Татарстан Республикасы көненә, җирле үзидарә көненә багышланган матди бүләкләү республика һәм федераль хакимият органнары күрсәтмәләре нигезендә түләнә торган пенсия, отпusклар, вакытлыча хезмәткә яраксызлык буенча пособиеләр исәпләү өчен уртача хезмәт хакы составында исәпкә алынмый.

6.3. Нигезләмәнең 4 бүлеге нигезендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүләр пенсияләрне, отпускларны, вакытлыча хезмәткә яраксызлык буенча

пособиеләрне исәпләп чыгару өчен уртача хезмәт хакы составында исәпкә алынмый һ.б.

6.4. Әлеге нигезләмәдә каралмаган, Министрлар Кабинеты карамагында исемләнгән һәм субсидияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла торган башка нигезләр буенча матди бүләкләү җирле бюджет исәбеннән бер мәртәбә бирелә торган премияләр, бер мәртәбә бирелә торган бюджетара трансфертлар пенсияләрне, отпускларны, вакытлыча хезмәткә яраксызлык буенча пособиеләрне исәпләү өчен уртача хезмәт хакы составында исәпкә алынмый.»

1.3. Нигезләмәнең 2 бүлегенең 2.3.пунктын түбәндәге эчтәлекле 7 абзац белән тулыландырырга:

-җитди сәбәпсез прогул ясаган, эшкә исерек хәлдә килгән, яисә эш көнендә дүрт сәгатьтән артык өзлексез яки гомумән алганда, җитди сәбәпсез эш көне дәвамында эштә булмаганнар, алынмаган гамәлләре булса,бу хезмәт дисциплинасын бозулар башкарган исәпләнгән чорда премия бирелми.

1.4. Нигезләмәнең 2 бүлегенең 2.2 пунктын түбәндәге эчтәлекле 9,10,11 абзацлар белән тулыландырырга:

«Премияне киметү гамәлгә ашырыла торган фактлар муниципаль хезмәткәрнең, хезмәткәрнең аңлатмалары, хезмәт язмалары, актлар һәм башка документлар белән расланырга тиеш.

Премияне киметү өчен сәбәпләр барлыгын күрсәтә.

Муниципаль хезмәткәр, хезмәткәр гамәл кылган очракта, җитәкче аңардан аңлатма язуы соратып алырга яисә аңлатмалардан баш тарту турында акт төзергә тиеш. Аңлатмада мәҗбүри тәртиптә хокук бозуны кылу сәбәпләре күрсәтелә. Тәкъдим ителгән документлар нигезендә турыдан-туры җитәкче тарафыннан эш нәтиҗәләре буенча премия күләмен киметү турындагы тәкъдимнәр белән муниципаль хезмәткәрнең гаебе дәрәҗәсе турында хезмәт язмасы төзелә.

Эш нәтиҗәләре буенча премияне киметү эштә кимчелекләр җибәрелгән булса яки хезмәт дисциплинасын бозган исәпләнгән чорда башкарыла, әгәр бу хата объектив сәбәпләр аркасында исәпләнгән чор тәмамланганнан соң (6 айдан да соңга калмыйча) ачыкланган очраклардан тыш.

2. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлегенә әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүматы порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Актаныш муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар аны рәсми бастырып чыгарганнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә һәм 01.01.2024 елдан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе Л.Р.Зарипов